БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 15 » сентябрь 2018 ел № 301

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы дәүләт яки муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын наймга алучылар өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьясы, "Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәт белән сыйфатсыз һәм (яки) билгеләнгән озынлыктан артып киткән тәнәфесләр белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтүдән баш тарткан очракта торак урынын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында" 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, "Дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наймга алучыларга торак урыныннан файдалану өчен түләү билгеләүнең методик күрсәтмәләрен раслау турында" 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номерлы Россия Төзелеш Министрлыгы боерыгы нигезендә, Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Балтач муниципаль районы дәүләт яки муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын наймга алучылар өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне расларга һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә (кушымта).

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.И. Шакиров